**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 17 июнь | № 444

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче, 2015 ел, 8 май, 333 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 –2020 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм дәүләт имтиханыннан иң начар нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллына карата (2 мәҗбүри предметка исәпләгәндә) бердәм дәүләт имтиханыннан иң яхшы нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллы (2

мәҗбүри предметка исәпләгәндә) чагыштырмасы 2020 елга 1,5 процент дәрәҗәсендә;»;

ярдәмче программаның 5 бүлегендәге таблицада:

«Бердәм дәүләт имтиханыннан иң начар нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллына карата (1 предметка исәпләгәндә) бердәм дәүләт имтиханыннан иң яхшы нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллы (1 предметка исәпләгәндә) чагыштырмасы, процент» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Бердәм дәүләт имтиханыннан иң начар нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллына карата (2 мәҗбүри предметка исәпләгәндә) бердәм дәүләт имтиханыннан иң яхшы нәтиҗәләр булган мәктәпләрнең 10 процентында бердәм дәүләт имтиханының уртача баллы (2 мәҗбүри предметка исәпләгәндә) чагыштырмасы 2020 елга 1,5 процент дәрәҗәсендә | 1,74 | 1,7 | 1,66 | 1,62 | 1,58 | 1,54 | 1,50»; |

ярдәмче программага кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\444.docx